КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 16 июнь г.Казань № 464

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2014 ел, 8 октябрь, 733 нче; 2015 ел, 7 август, 574 нче; 2016 ел, 1 сентябрь, 608 нче; 2017 ел, 16 гыйнвар, 10 нчы; 2018 ел, 23 апрель, 280 нче, 2019 ел, 22 октябрь, 951 нче, 2020 ел, 4 декабрь, 1095 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә, 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«11. Файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы яисә файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгаруны берләштерелгән лицензия буенча гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү,

разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү яисә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен берләштерелгән лицензия буенча, аларга бирелгән «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә үз җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен расланган техник проект нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга хокуклы:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару;

җир асты суларын җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итүнең федераль органы билгеләгән тәртиптә чыгару.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин